ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 елның «25» августыннан № 424

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2016 елның 01 октябреннән Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» 2016 елның 28 сентябрендәге 388 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 17 февралендәге 181 номерлы карары һәм «2016 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр күләме турында» 2015 елның 23 сентябрендәге 698 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. «Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында туклануны оештыру турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 сентябрендәге 388 номерлы карарын түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

- «7. Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына түләүсез туклануны оештыру буенча социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан һәм, билгеләгән форматларга туры китереп, Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы аша алынырга мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**